**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ МАЛОЕЛГИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

422619, с. Малая Елга
ул.Советская, д.58
тел: 8-(84378) -3-25-16
факс: 8-(84378) -3-25-16
e-mail:Melg.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЕЧЕ ЕЛГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

422619, Keче Елга авылы,
Совет урамы, 58нче йорт,
тел: 8-(84378) -3-25-16
факс: 8-(84378) -3-25-16
e-mail:Melg.La@tatar.ru

**2024 елның 8 ноябре** **52 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры вазыйфаи оклады күләмен арттыру турында (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш)**

Социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры хезмәтенә түләүне тәртипкә салу максатларында (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш), Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 26 апрелендәге 7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның хезмәт хакы түбәндәге зурлыкта билгеләнә:

| Вазифа | Халык саны белән муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |
|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр |
| Баш бухгалтер | 25 700 рублей |

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлеге башкарма комитетының штат расписаниесенә баш бухгалтер вазифасын кертү шарты булып муниципаль берәмлек халкының саны 3,5 мең кешедән артык.».

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә

4. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Кече Елга**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Р.З.Хисамов**